ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» май 2019 ел. № 198

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының
30.04.2019 №168 «МБУ “Үзәкләштерелгән бухгалтерия"
хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләүне оештыру һәм шартлары”
турында карарга үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетынын 30.04.2019 №168 санлы “«Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында"гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3нче пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.1. санлы бүлек белән тулыландырырга:

«3.1. Әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы күләме, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме үзгәрмәү һәм алар тарафыннан шул ук квалификациягә туры килгән эшләр башкару шарты белән, 2019 елның 31 мартына түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.С. Авдеев**